ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм $32^{1}$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 491-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

---

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм $32^{1}$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 491-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе  Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 2 ноябре
№ 2220-VI ДС

491-б номерлы проект
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32[1] статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 32 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарның Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында даими яшәве турындагы әлеге пунктның 1 пунктчасында каралган таләп, әгәр ата-ананың берсе яки бердәнбер ата яки ана хәрби хезмәткәр статусына ия булса, кулланылмый.»;

2) 32[1] статьяның 10 пунктында:

а) түбәндәге эчтәлектәге 10 пунктны өстәргә:

10) «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәрнең статусын раслаучы документ (әгәр ата-ананың берсе яки бердәнбер ата яки ана хәрби хезмәткәр статусына ия булса).»;

б) түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Әгәр гариза бирүче «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәр статусында булса, әлеге пунктның 9 пунктчасында күрсәтелгән документ бирелми.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32[1] статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектына АҢЛАТМА**

Закон проекты 2023 елның 25 апрелендәге 9/34 номерлы «түгәрәк өстәл» нәтиҗәләре буенча, әгәр ата-ананың берсе яки бердәнбер ата яки ана, әгәр уллыкка алучыларның берсе яки икесе дә «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәр статусына ия булса, Россия Федерациясе Федераль Җыены Федерация Советының Аграр-азык-төлек сәясәте һәм табигатьтән файдалану комитетының Россия Федерациясе субъектларына өч һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарның билгеле бер вакыт эчендә үз территорияләрендә яшәү кирәклеге турындагы таләпне кире кагарга киңәш ителәә торган карарын тормышка ашыру максатларында эшләнгән.

Татарстан Республикасы территориясендә өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлеге бирү өчен кирәкле шартлар булып мохтаҗлык һәм соңгы биш елда Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү факты тора (Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 статьясы).

Татарстан Республикасында 2023 елның 1 июненә 98 хәрби хезмәткәр гаиләсе җир кишәрлекләре алу исемлегенә кертелгән, шуларның 48е җир кишәрлекләре белән тәэмин ителмәгән (кушымтаны карагыз).

Тәкъдимнәрне исәпкә алып эшләнгән закон проекты белән дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдән өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга бушлай милеккә җир кишәрлеген бирүгә (тапшыруга) мөнәсәбәттә билгеләнгән җир кишәрлеген бирү турында гариза бирү көненә кадәр соңгы биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү турындагы таләпне, әгәр ата-ананың берсе яки бердәнбер ата яки ана «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәр статусына ия булса, алып ташларга тәкъдим ителә.

Закон проектының 1 статьясының 2 пункты белән җир участогы бирү турындагы гаризага кушылган документлар исемлеген «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткәрнең статусын раслаучы документ белән тулыландырырга тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32[1] статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32[1] статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32[1] статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы закон проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32[1] статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.